ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 580-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 580-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәмmәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2572-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3, № 4, № 7 (I өлеш); 2016, № 1 – 2; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 27 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми:»;

2) түбәндәге эчтәлектәге $2^1$ пунктны өстәргә:
«$2^1$) күпфатирлы йортларда һәм (яки) аларга якын территорияләрдә урнашкан җәмәгать туклануы объектларында (рестораннардан тыш) җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә 22 сәгатьтән алып 10 сәгатькә кадәр;»;

3) 3 пунктның беренче абзацында «50 квадрат метрдан кимрәк» сүзләре алдыннан «кунакларга хезмәт күрсәтүнең сезонлы залы (зонасы) мәйданын исәпкә алмыйча» сүзләрен өстәргә;

4) 4 пунктта «100 квадрат метрдан кимрәк» сүзләре алдыннан «кунакларга хезмәт күрсәтүнең сезонлы залы (зонасы) мәйданын исәпкә алмыйча» сүзләрен өстәргә;

5) түбәндәге эчтәлектәге 2 өлешне өстәргә:
«2. Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә сыра һәм сыра эчемлекләре, сидр, пуаре, әче балны ваклап сату бары

тик рестораннар, барлар, кафелар, буфетлар, шул исәптән күпфатирлы йортларда һәм (яки) аларга якын территорияләрдә урнашкан җәмәгать туклануы объектларында гына башкарыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, әлеге статьяда аларның үз көченә керүенең башка вакыты билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш.

2. Әлеге Законның 1 статьясының 1, 2 һәм 5 пунктлары 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясының 3 һәм 4 пунктлары нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) 2024 елның 1 июненнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

Закон проекты федераль законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә эшләнгән.

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 14 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектларына бирелә:

җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә рестораннар, барлар, кафелар, буфетлар. шул исәптән күпфатирлы йортларда һәм (яки) аларга якын территорияләрдә урнашкан җәмәгать туклануы объектларында гына сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны ваклап сатуны гамәлгә ашыру турындагы таләпне билгеләү хокукы;

күпфатирлы йортларда һәм (яки) аларга якын территорияләрдә урнашкан җәмәгать туклануы объектларында (рестораннардан тыш) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә Россия Федерациясе субъектлары законнары белән билгеләнгән шартлар (җәмәгать туклануы объектлары урнашкан урыннарны да кертеп) һәм тәртип нигезләрендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү хокукы.

Әлеге закон проектына бәйле рәвештә 2025 елның 1 мартыннан тәкъдим ителә:

җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә сыра һәм сыра эчемлекләрен, сидрны, пуарены, әче балны рестораннар, барлар, кафелар, буфетлар, шул исәптән күпфатирлы йортларда һәм (яки) аларга якын территорияләрдә урнашкан җәмәгать туклануы объектларында гына ваклап сатуны гамәлгә ашыру турында таләпне билгеләргә;

күпфатирлы йортларда һәм (яки) аларга якын территорияләрдә урнашкан җәмәгать туклануы объектларында (рестораннардан тыш) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын 22 сәгатьтән алып 10 сәгатькә кадәр чикләргә.

Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә сыра һәм сыра эчемлекләре, сидр, пуаре, әче бал сату буенча эшчәнлекне 1428 сәүдә объекты башкара, шуларның 299ы күпфатирлы йортларда урнашкан. Күрсәтелгән сәүдә объектлары рестораннар, барлар, кафелар һәм буфетлар булып тора, моңа бәйле рәвештә, закон проектының 1 статьясының 2 өлеше нормасын кертү Татарстан Республикасы икътисадына йогынты ясамаячак.

299 сәүдә объектының 54е – рестораннар, шуңа бәйле рәвештә әлеге сәүдә объектларына закон проекты тәкъдим иткән алкоголь продукциясен сату вакытын

җирле вакыт буенча 22 сәгатьтән 10 сәгатькә кадәр чикләү кагылмый. Калган 245 сәүдә объектының 186сы Казан шәһәрендә. Шулай итеп, Казан шәһәреннән кала, тәкъдим ителгән чикләүләр Татарстан Республикасының бөтен территориясендәге 59 объектка тәэсир итәчәк.

Закон проекты беренче катларында алкоголь продукциясен сатучы җәмәгать туклануы объектлары урнаштырылган күпфатирлы йортларда яшәүче гражданнарның уңайлы яшәү шартларын тәэмин итүгә, шулай ук криминоген хәлнең кимүенә ярдәм итәчәк.

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 29 маендагы 102-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 2 статьясы белән кунакларга хезмәт күрсәтүнең сезонлы залы (зонасы) дигән төшенчә кертелде, бу төшенчә белән җәмәгать туклануы объектына якын территориядә урнашкан яки җәмәгать туклануы объектына яки мондый объект урнашкан бинага (урынга) тоташкан, билгеле бер вакыт (сезон) дәвамында җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәтү өчен билгеләнгән вакытлыча корылма һәм (яки) вакытлыча конструкция аңлатыла.

Закон проекты белән югарыда күрсәтелгән федераль законны исәпкә алып, залның гомуми мәйданында кунакларга хезмәт күрсәтүнең сезонлы залы (зонасы) мәйданы исәпкә алынмый дигән төзәтмә кертү күздә тотыла. Әлеге төзәтмәләр 2024 елның 1 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.